Subsequently, these studies were continued by F. Yusupov in his monographs "South Ural and Trans-Ural Dialects" (1979), "Tatar Dialects. Ural Subdialects" (2003), "Krasnoufimsky Tatars: History, Language, Folklore" (2003), "Safakulevsky Tatars: History, Language, Folk Art" (2006). These works, using linguistic geography and system-synchronous methods, explore the origins, ethnic history and main linguistic features of the Krasnoufimsky, Vyatka-Kistinsky, Ichkinsky, Nagaibaksky, Safakulevsky subdialects, widespread in the geographical area of the Urals. In addition to linguistic materials, the use of archival materials and historical sources significantly increased the relevance and scientific value of these monographs and provided a powerful basis for clarifying the place of the subdialects in the Tatar dialect system.

F. Yusupov developed and improved these research results in his monographs "Nonlinear Verb Forms in Dialects of the Tatar Language" (1985), "Study of the Tatar Verb" (1986), in numerous articles and speeches. His monograph "Morphology of the Tatar Dialect Language" (2004) was recommended by the Educational and Methodological Association for Philology under the Ministry of Education and Science of Russia as a textbook for national departments of classical universities of the Russian Federation and was awarded the title of the best scientific work of 2005 at a competition among the works in humanities completed at Kazan State University.

F. Yusupov is still carrying out extensive work in the field of systemic research into Tatar dialects. His work "Dialects of the Kazan Tatars" (2023), the result of his many years of scientific research, explores the period of the Kazan Khanate, the history of the emergence of the Kazan Tatars' dialect, which after the collapse of the Kazan Khanate formed the basis of the Tatar literary language. To clarify the territorial relationships of the Kazan Tatars' dialects with other Turkic languages, the scholar widely uses linguistic methods [26].

Tatar dialectology studies continued at Kazan University in the late 20th–early 21st centuries. Enumerating the works of our famous scholars, who conduct their research in this field, we can name the candidate and doctoral dissertations on Tatar dialectology by G. Sungatov, M. Sattarova (Khabibullina), G. Faizullina and others. In 1988–1989, dialectological expeditions were organized headed by G. Sungatov, to study the language of the Sazov Region Tatars in the Tyumen Region, when the phonetic system of the dialect was experimentally studied [27]. M. Sattarova studied variants of the phoneme [a] in the Tatar dialect and determined the breadth of its distribution [28]. In her doctoral dissertation, G. Faizullina studied the transfer of the image of a person in the dialect language in the linguocultural aspect, her research is based on the material of Tatar folk subdialects, widespread in the south of the Tyumen Region [29].

Expeditionary research into Tatar dialects and subdialects is still in progress at Kazan University: G. Galiullina, A. Yusupova, E. Kadyrova conducted a scientific processing of the materials collected during dialectological expeditions, studying the samples of spoken language of the Tatars living in the Republics of Mordovia and Chuvashia, the Penza Region in 2015–2016, and published their monographs [30, p. 9].

Teachers from Kazan University make great contributions to the monographic study of the individual Tatar subdialects. For example, the monograph by Z. Kirillova, co-authored with the Turkish University Prof. Firat Erzhan Alkaya, studies the dialects of the Kryashen Tatars and describes their linguistic and cultural features [31]; in addition, numerous articles are published aimed at a historical and comparative study of the linguistic features characterizing the Tatar dialects [32; 33].

In recent years, teachers and scholars of the Tatar Linguistics Department have been actively working to reintroduce the scientific heritage of outstanding dialectologists and Turkologists into scientific circulation and present them to the general public: these are the materials collected by the historian of the St. Petersburg Academy of Sciences, Prof. G. Miller (1705–1783) during the Great Northern Expedition (1733–1743) and have remained unnoticed so far [2, p. 267]. It is important that these manuscripts and dictionaries should be primary sources in the study of the Tatar subdialects.

The study of the history of the Tatar dialects and subdialects formation, the study of individual ethnic groups and their linguistic systems based on linguistic features reflected in the written monuments of the 19$^{th}$ – early 20$^{th}$ centuries, remain relevant issues in Tatar linguistics; in this field, we can highlight the articles of F. Nurieva [34; 35].

Particular attention at the Department of Tatar Linguistics is paid to increasing the number of young researchers in the field of Tatar dialectology. In the first quarter of the 21$^{st}$ century, dialectological expeditions continue their work (they were headed first by E. Kadyrova, later by A. Yusupov); teachers and students of the university go to different regions of Russia and collect samples of local speech. Thus, dialectological expeditions were organized to the Safakulevsky and Shadrinsky Districts of the Kurgan Region (2005–2007), the Tyumen Region (2012–2013), the Nizhny Novgorod Region (2015), the Republic of Mordovia and the Penza Region (2015), and the Chuvash Republic (2016). In recent years, students have been on expeditions to the Zakazansky Regions of the Republic of Tatarstan – the Vysokogorsky (2019), Arsky (2021), Atninsky (2023) Regions.

## Main results

Turkology and Tatar linguistics have accumulated a wealth of experience in the study of the Tatar dialects. It should be noted that the scientific research into the Tatar dialects and subdialects at Kazan University has been carried out consistently and systematically from the day the University was opened to the present time: in the first half of the 19$^{th}$ century (1804–1854), the study of the history of the Tatar people, their ethnography and the issues of dialectology developed in connection with the activities of the Eastern Division. In the second half of the 19$^{th}$ and early 20$^{th}$ centuries (1855–1917), a significant place in the study of the Tatar dialects was occupied by the activities of the University "Society of Archaeology, History and Ethnography," which laid the foundations of Tatar dialectology as a science. At the turn of the 20$^{th}$ and in the early 21$^{st}$ centuries, within Tatar dialectology, different scientific schools were formed. In each period of the Tatar dialectology history, university scholars made significant contributions to the scientific research, laid the foundations of new trends and conducted active research in this field, teaching students who defended their candidate and doctoral dissertations. During this period, L. Zalyai, D. Tumasheva, G. Sattarov, F. Yusupov, G. Sungatov, E. Kadyrova, O. Khisamov and A. Yusupov were among those who took part in teaching students the subject of dialectology and conducted scientific research, organizing expeditions in the territory of the Tatars' compact residence.

Kazan University has made a great contribution to the development of Turkology and Tatar linguistics through enhancing scientific exchange. At several departments of the university, numerous dissertations on Tatar dialectology of various levels are being worked on and defended at the Dissertation Councils, new candidates and doctors of science are being prepared. The Department holds research and practice conferences, memorial evenings dedicated to the heritage of the scholars who made significant contributions to the study of the Tatar language history and Tatar dialectology. Its faculty publish collections of research papers and conference materials.

Over the years, Kazan University has accumulated a wealth of experience in teaching Tatar dialectology to students. Based on systematization of the scientific research results, textbooks, teaching aids and programs for teaching students have been written, and a system of scientific and methodological trends that is stable to date has been created.

**References**

1. Miller, G. F. (1791). *Opisanie zhivushchikh v Kazanskoi gubernii yazycheskikh narodov, yako to cheremis, chuvash i votyakov: s pokazaniem ikh zhitel'stva, politicheskogo uchrezhdeniya ...* [Description of the Pagan Peoples Living in the Kazan Province, such as the Cheremis, Chuvash and Votyaks: With Evidence of Their Residence, Political Institution...]. 99, [2] s., [8] p. St. Petersburg, Imp. Akad. Nauk. (In Russian)

2. Nurieva, F. Sh., Galiullina, G. R., Yusupov, A. F. (2023). *G. F. Miller's Dictionary "Description of Pagan Peoples Living in Kazan Province, such as Cheremis, Chuvash and Votyaks..." as a Valuable Source for Studying the Tatar Language of the 18th Century (based on LingvoDoc material).* Trudy ISP RAN/Proc. ISP RAS, vol. 35, issue 6, pp. 265–282. (In English)

3. Miller, G. F. (1937). *Istoriya Sibiri* [History of Siberia]. 1937–1941. T. 1. 608 p. Moscow-Leningrad, izd-vo Akad. nauk SSSR. (In Russian)

4. *Tatar khalyk səilәshlәre: ike kitapta* (2008) [Tatar Folk Dialects: In Two Books]. Kollektiv avtorov: F. S. Bayazitova i dr. Kniga. 1. 461 p. Kazan', Prosveshchenie. (In Tatar)

5. Makhmudov, M. G. (1851). *Ylgәn kebek bulgan keshelәrne kabergә kymmәkdin saklaunyң gamәllәre bәyanyndadyr* [On the Protection of the Nearly Dead from Burial]. Kazan', 82 p. (In Tatar)

6. Makhmudov, M. G. (1857). *Prakticheskoe rukovodstvo k izucheniyu tatarskogo yazyka* [A Practical Guide to Learning the Tatar Language]. Kazan', izd-vo knigoprodavtsa Ivana Dubrovina. (In Russian)

7. *Kazanskaya lingvisticheskaya shkola: Kniga pervaya: Kazanskaya tyurkskaya lingvisticheskaya shkola* (2008) [Kazan Linguistic School: Book One: Kazan Turkic Linguistic School]. Sost. M. Z. Zakiev. 255 p. Kazan', Tatar. kn. izd-vo. (In Russian)

8. Bessonov, A. G. (1881). *O govorakh kazanskogo tatarskogo narechiya i ob otnoshenii ego k blizhaishim k nemu narechiyam i yazykam* [On the Accents of the Kazan Tatar Dialect and Its Relationship to the Dialects and Languages Closest to It]. Zhurnal Ministerstva narodnogo prosveshcheniya. CH. CCXVI (avgust). Pp. 200–242. St. Peterburg. Tipografiya V. S. Balasheva. (In Russian)

9. *Protokoly obshchikh sobranii Obshchestva arkheologii, istorii i ehtnografii za 1898 g.* (1899) [Minutes of the General Meetings of the Society of Archaeology, History and Ethnography of 1898]. Izvestiya Obshchestva arkheologii, istorii i ehtnografii pri Kazan. universitete. T. 15, Vyp. 4, pp. 442–482. (In Russian)

10. *Otchet o poezdke, sovershennoi s 1 iyunya 1897 g. po 20 avgusta togo zhe goda v Belebeevskii i Menzelinskii uezdy Ufimskoi gubernii* (1898) [Report on a Trip Made from June 1, 1897 to August 20 of the Same Year to the Belebeevsky and Menzelinsky Districts of the Ufa Province]. Uchenye zapiski Kazanskogo universiteta. Kn. 11, pp. 1–37. Kazan'. (In Russian)

11. *Otchet o poezdke, sovershennoi s 20 maya po 20 avgusta 1898 g. v Belebeevskii uezd Ufimskoi gubernii* (1900) [Report on a Trip Made from May 20 to August 20, 1898 to the Belebeevsky District of the Ufa Province]. Uchenye zapiski Kazanskogo universiteta. Kn. 7 i 8. Pp. 1–30. Kazan' (In Russian)

12. *Otchet o poezdke v Minusinskii uezd Eniseiskoi gubernii, sovershennoi po porucheniyu istoriko-filologicheskogo fakul'teta imperatorskogo Kazan. universiteta, letom 1899 goda* (1900) [Report on a Trip to the Minusinsk District of the Yenisei Province, Made on Behalf of the Historical and Philological Faculty of the Imperial Kazan. University, Summer 1899.]. Kazan', 59 p. (In Russian)

13. Malov, E. A. (1885). *Svedeniya o misharyakh: ehtnograficheskii ocherk* [Information about the Mishars: An Ethnographic Sketch]. Izvestiya Obshchestva arkheologii, istorii i ehtnografii. T. 4, pp. 13–91. (In Russian)

14. Malov, E. A. (1904). *Iz poezdki k misharyam (o narechii misharei Chistopol'skogo uezda)* [From a Trip to the Mishars (about the Mishar dialect of the Chistopol District)]. Prilozhenie k "Uchenye zapiski Kazanskogo universiteta". Kn. 4, pp. 1–24. Kazan', Tipografiya litogr. un-ta. (In Russian)

15. Magnitskii, V. K. (1896). *Neskol'ko dannykh o misharyakh (meshchera, meshcheryaki) i seleniyakh ikh v Kazanskoi i Simbirskoi guberniyakh* [Some Information about the Mishars (Meshchera, Meshcheryaks) and Their Villages in the Kazan and Simbirsk Provinces]. Izvestiya Obshchestva arkheologii, istorii i ehtnografii. T. 13. Vyp. 4, pp. 245–257. (In Russian)

16. Kazarinov, V. A. (1895). *O misharyakh v Chistopol'skom uezde Kazanskoi gubernii* [On the Mishars in the Chistopol District of the Kazan Province]. Izvestiya Obshchestva arkheologii, istorii i ehtnografii. T. 4, pp. 1–12. (In Russian)

17. Akhmarov, G. N. (1903). *O yazyke i narodnosti misharei* [On the Language and Nationality of the Mishars]. Izvestiya Obshchestva arkheologii, istorii i ehtnografii pri Kazan. universitete. T. 19. Vyp. 2, pp. 91–160. (In Russian)

18. Salakhova, E. K. (2016). *Problema proiskhozhdeniya tatar-misharei i teptyarei v trudakh G. N. Akhmarova* [The Issue of the Tatar-Mishars and Teptyars' Origins in the Works of G. N. Akhmarov]. Istoricheskaya ehtnologiya. T. 1. No. 2, pp. 349–362. (In Russian)

19. Mardanova, F. F. (2020). *Rol' Kazanskogo universiteta v izuchenii dukhovnoi kul'tury tatar Povolzh'ya* [The Role of Kazan University in the Study of the Volga Tatars' Spiritual Culture]. Uchenye zapiski Kazanskogo universiteta. Ser. Gumanit. nauki. T. 162, Kn. 3, pp. 181–195. (In Russian)

20. Akhmarov, G. N. (1908). *Teptyari i ikh proiskhozhdenie* [The Teptyars' and Their Origins]. Izvestiya Obshchestva arkheologii, istorii i ehtnografii

pri Kazan. universitete. T. 23, Vyp. 5, pp. 340–364. (In Russian)

21. Salakhova, E. K. (2016). *Problema proiskhozhdeniya tatar-misharei i teptyarei v trudakh G. N. Akhmarova* [The Issue of the Tatar-Mishars and Teptyars' Origins in the works of G. N. Akhmarov]. Istoricheskaya ehtnologiya. T. 1. No. 2, pp. 349–362. (In Russian)

22. Validi, Dzh. (1927). *O dialektakh kazanskogo tatarskogo yazyka* (1927) [On the Dialects of the Kazan Tatar Language]. Vestnik nauchnogo obshchestva tatarovedeniya. No. 6, pp. 50–65. (In Russian)

23. Validi, Dzh. (1929). *Nokrat həm Glazov tatarlary arasynda* [Among the Tatars of the Vyatka and Glazov]. Tatarstan. No. 5, pp. 40–42. (In Tatar)

24. Validi, Dzh. (1930). *Narechie karinskikh i glazovskikh tatar* [The Dialect of the Karin and Glazov Tatars]. Trudy obshchestva izucheniya Tatarstana. T. 1, pp. 135–144. (In Russian)

25. Validi, Dzh. (1947). *Tatar dialektologiyase: yugary uku iortlary həm pedagogiya uchilishchelary studentlary өchen dəreslek.* [Tatar Dialectology: A Textbook for Students of Universities and Teacher Training Colleges]. 137 p. Kazan'. (In Tatar)

26. Yusupov, F. Yu. (2023). *Kazan tatarlary shivəse.* [Kazan Tatar Dialects]. 993 p. Kazan', Tatar. knizh. izd. (In Tatar)

27. Sungatov, G. M. (1991). *Foneticheskaya sistema zabolotnogo govora tobolo-irtyshskogo dialekta sibirskikh tatar (ehksperimental'no-foneticheskoe issledovanie): avtoref. dis. ... kand. filol. nauk* [Phonetic System of the Swamp Dialect of the Siberian Tatars' Tobol-Irtysh Dialect (an experimental phonetic study): Ph.D. Thesis Abstract]. Kazan', 23 p. (In Russian)

28. Khabibullina, M. R. (2002). *Kharakteristika izogloss variantov fonemy [a] v tatarskom lingvinistichekom prostranstve: dis. ... kand. filol. nauk* [Characteristics of Isogloss Variants of the Phoneme [a] in the Tatar Linguistic Space: Ph.D. Thesis]. Kazan', 173 p. (In Russian)

29. Faizullina, G. Ch. (2017). *Obraz cheloveka v dialektnoi yazykovoi kartine mira (na materiale tatarskikh narodnykh govorov yuga Tyumenskoi oblasti): diss. ... d-ra filol. nauk* [The Image of a Person in the Dialectal Linguistic Picture of the World (based on the Tatar folk dialects in the south of the Tyumen Region): Doctoral Thesis]. Kazan', 406 p. (In Russian)

30. Kadirova, Eh. Kh., Galiullina, G. R., Saifulina, F. S., Yusupova, A. Sh. (2015). *Mordoviya Respublikasy həm Penza өlkəse tatarlary: dialektologiya həm khalyk avyz iҗәaty materiallary* [Tatars of the Republic of Mordovia and the Penza Region: Materials on Dialectology and Oral Folk Art]. 313 p. Kazan'. (In Tatar)

31. Alkaya, E., Kirillova, Z. (2018). *Kreşin Tatar Türkçesi (Dil, Tarih, Kültür)* [Tatar Turkish Relationships (Language, History, Culture)]. 670 p. İstanbul, Kesit Yay. (In Turkish)

32. Kirillova, Z. N., Alkaya, A. (2018). *Kerəshen tatarlary sөiləshlərenең leksik үzenchəleklәre* [Lexical Features of the Kryashen Tatars' Dialects]. Tatarica. No. 2 (11), pp. 7–30. (In Tatar)

33. Yusupov, A. F. (2023). *Russkie zaimstvovaniya v tatarskikh govorakh: osobennosti funktsionirovaniya i adaptatsii* [Borrowings in the Tatar Dialects: Function and Adaptation Features]. Filologiya i kul'tura. Philology and Culture. No. 3 (73), pp. 81–86. (In Russian)

34. Normanskaya, Yu. V., Nurieva, F. Sh. *Grafiko-foneticheskie osobennosti dialektov tatar-kryashen v kontse XIX – nachale XX v.* [Graphic and Phonetic Features of the Tatar-Kryashen Dialects in the late 19th–early 20th Centuries]. Kirillicheskie pamyatniki na ural'skikh i altaiskikh yazykakh. I tom. Grafiko-foneticheskie osobennosti knig XIX v. Pp. 339–354. Moscow, izd. gruppa "Al'ma Mater". (In Russian)

35. Nurieva, F. Sh. *Yazykovoi pamyatnik govora sergachskikh misharei: tekst ispovedi XIX v.* [Linguistic Monument of the Sergach Mishar Dialect: The Text of the Confession of the 19th Century]. Kirillicheskie pamyatniki na ural'skikh i altaiskikh yazykakh. I tom. Grafiko-foneticheskie osobennosti knig XIX v. Pp. 354–370. Moscow, izd. gruppa "Al'ma Mater". (In Russian)

# КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫНДА ТАТАР ДИАЛЕКТОЛОГИЯСЕ МӘКТӘБЕ: АЛШАРТЛАРЫ, ФОРМАЛАШУЫ ҺӘМ ҮСЕШЕ

**Айрат Фаик улы Юсупов,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
faikovich@mail.ru.

**Гүзәл Җәгъфәр кызы Фәйзуллина,**
Төмән дәүләт университеты,
Россия, 625003, Төмән ш., Володарский ур., 6 йорт,
utgus@mail.ru.

Татар тел белемендә төп бурычы җирле төбәкләрдә яшәп килә торган җанлы сөйләм телен, ягъни җирле сөйләшләрне өйрәнү булган диалектология – алга киткән фәнни юнәлешләрнең берсе. Ул халык сөйләм теленең әдәби телгә керми калган күренешләрен тикшерә, фәнни анализлый, аларның таралыш территориясен билгели.

Татар халкының рухи мәдәниятен, төрле этник төркемнәрнең тарихын, тел үзенчәлекләрен, аларның көнкүрешен һәм яшәү рәвешен, гореф-гадәтләрен өйрәнү юнәлешендә берничә гасыр дәвамында эзлекле, системалы фәнни эш алып барылган. Җанлы сөйләм телен өйрәнү, татар теленең аерым сөйләшләре һәм диалектларына караган материалларны теркәү, фактик материал җыю, аларга фәнни аңлатма бирү эше XVIII гасырның беренче яртысында ук башлана. Казан университетында татар диалектологиясе мәсьәләләрен фәнни өйрәнүнең дә ике гасырдан артык тарихы бар, һәм бу юнәлештә бай тәҗрибә тупланган, университетта татар диалектлары һәм сөйләшләрен тикшерү традицияләре хәзерге вакытта да дәвам итә, татар теле белеме кафедрасының фәнни юнәлешләре арасында чор таләп иткән актуаль мәсьәләләрнең берсе булып кала. Әлеге мәкаләдә Казан университетында диалектология мәктәбенең формалашуы һәм үсеше төп өйрәнү объекты итеп куела, беренче мәртәбә системалы төстә өйрәнелә. Бу мәкаләнең фәнни яңалыгын һәм актуальлеген тәшкил итә. Уку йортындагы әлеге фәнни мәктәп тарихын өйрәнү татар диалектологиясен өйрәнүгә зур өлеш керткән күренекле галимнәрнең гыйльми эшчәнлеген, аларның фәнни-методик мирасын тикшерү белән янәшә алып барыла.

**Төп төшенчәләр:** татар диалектологиясе, татар галимнәре, галим-диалектологлар, татар теле кафедрасы, Казан университеты

## Кереш

Тел белеме өлкәсендәге фәнни тикшеренүләрдә татар диалектологиясен өйрәнүнең берничә этабы аерып куела. Татар сөйләм теленә һәм җирле сөйләшләргә, татар диалектларына караган материалларны теркәү, аларга тегe яки бу күләмдә аңлатма бирү XVIII гасырның беренче яртысында ук башлана. Әлеге чорда рухи һәм матди мәдәният элементлары ачыклана, татарлар компактлы яшәгән аерым территорияләрдә Г. Ф. Миллер, И. Георги, Ф.-И. Страленберг, П. С. Паллас һ. б. кебек төрле эшлекләләр, тарихчы-галимнәр тарафыннан лексик материал туплана. Татар җанлы сөйләү материалларын җыю һәм соңрак фәнни яктан эшкәртү эше Санкт-Петербург Фәннәр академиясе профессоры, тарихчы Г. Ф. Миллер (1705–1783) катнашкан Бөек Төньяк экспедициясеннән (1733–1743) башлана.

Г. Ф. Миллер Россиядәге фәнни эшчәнлеген (ул 1725 елда Санкт-Петербург шәһәренә килә) Петр I нең Россия дәүләте территорияләрен һәм телләрен, беренче чиратта, аның көнчыгыш төбәкләрен һәрьяклап өйрәнү өчен академик экспедицияләр оештыру турындагы идеяләрен тормышка ашыру елларында башлап җибәрә. Себердәге эчке төбәкләрнең табигатен һәм табигый байлыкларын, тарихын һәм җирле халыкларның этнографиясен өйрәнү академик отрядта катнашучыларга йөкләнә, аның җитәкчесе итеп Г. Ф. Миллер билгеләнә. Академик отрядның Себер буйлап сәяхәте Бөек Төньяк экспедициясе кысаларында (1733–1743) уза.

Г. Ф. Миллерның Себергә экспедиция юлы Казан аша уза, шул максаттан ул 1733 елның 18 октябрендә Казан губернасына килә, биредә Санкт-Петербург Фәннәр академиясе йөкләмәсе буенча Идел буе халыкларының мәдәни тормышы һәм көнкүреше үзенчәлек-

ләре турында мәгълүматлар җыя. Губерна чикләрендә алып барган эшчәнлеге нәтиҗәсендә җитди академик эшләргә нигез салына, аерым алганда, галимнең «Описание живущих в Казанской губернии языческих народов, яко то черемис, чуваш и вотяков: с показанием их жительства, политического учреждения...» (1791) хезмәте дөнья күрә [1]. Кызганычка каршы, соңгы елларга кадәр әлеге хезмәткә, галимнең татар диалектларын өйрәнүдәге эшчәнлегенә тиешле игътибар бирелмәде. Хезмәтнең сүзлек өлеше 81–99 битләрдә урнаштырылып, Идел-Урал төбәгендә яшәгән халыкларының телләрендә (барлыгы 8 телдә) 2650 дән артык сүз формасы туплана. Татар телендәге 325 тән артык сүзформа тәкъдим ителә, ул сүзлекнең 82, 84, 86, 88, 90, 92, 94, 96, 98 битендә урын алган [2, б. 267].

Г. Ф. Миллерның «Себер тарихы» (1937) дигән икенче зур күләмле хезмәтендә себер татарларының барлык диалектларыннан җыелган лексика тәкъдим ителә, тел материаллары нигезендә халыкның тарихын тикшерү, аның этнонимик үзлекләрен ачу омтылышы ясала, мәсәлән, хезмәттә *Бараба, Тура* сүзләренең этимологиясе турында фикерләр китерелеп, аларның мәгънә төсмерләре күрсәтелә [3, б. 185–189].

Шулай итеп, җанлы сөйләм телен өйрәнү, татар теленең аерым сөйләшләре һәм диалектларына караган материалларны теркәү, фактик материал җыю, аларга фәнни аңлатма бирү эше XVIII гасырның беренче яртысыннан ук юл ала.

## Тикшеренү материаллары һәм методлары

Әлеге мәкаләдә Казан университетында татар диалектологиясен фәнни яссылыкта өйрәнү тарихы, студентларга диалектология предметын укыту мәсьәләләре хронологик аспектта тасвирлана; татар диалектологиясе өлкәсендә хезмәт иткән һәм фәнни тикшеренүләр алып барган галим-диалектологларның фәнни-методик мирасын ачыклау, аларның хезмәтләренә күзәтү ясау һәм бүгенге көн күзлегеннән бәя бирү максаты куела.

Фәнни тикшерү барышында төп методлары буларак, *биографик метод, тасвирлама, тарихи-чагыштырмалы һәм аксиологик методлар* кулланылды. Биографик һәм тасвирлама методлар ярдәмендә татар диалектлары, сөйләшләрен өйрәнүче галимнәрнең фәнни эшчәнлеге тикшерелде; тарихи-чагыштырмалы һәм аксиологик методлар галим-диалектологларның фәнни-методик эшчәнлеген бәяләгәндә ярдәм итте.

## Фикер алышу

1804 нче елның ноябрендә Казан университеты ачылуга ук тюркология өлкәсендәге фәнни тикшеренү һәм эзләнүләр учагына әверелә. Казан университеты үзенең барлыкка килгән көннәреннән бирле Россиядә төрки тел белеме һәм тюркология өлкәсендәге тикшеренүләрнең бишеге булып тора. XIX гасырның 10 елларында ук тюркология өлкәсендәге фәнни-тикшеренү эшчәнлегендә җанланыш күзәтелә башлый. Бу этапта Казан университетында яңа фәнни тикшеренүләр башлана, төрки телләрнең фәнни нигезләрен тирәнрәк өйрәнү һәм эшләү юлында беренче адымнар ясала.

Билгеле булганча, XIX гасырның беренче яртысында университетта унга якын көнчыгыш теле укытыла (мәсәлән, гарәп, фарсы, татар, төрек, кытай, монгол, әрмән телләре, аерым елларда яһүд һәм сүрия телләре өстәлә) шуның белән бергә бу халыкларның тарихын, аларның телләрен, көнкүрешен һәм яшәү рәвешен, гореф-гадәтләрен өйрәнү юнәлешендә дә фәнни эш алып барыла. Шунысын да ассызыклап китү кирәк: әлеге чорда көнчыгыш телләрен бу дәрәҗәдә мондый күләмдә өйрәнү Россиядәге университетларның берсендә дә (Мәскәү, Санкт-Петербург, Харьков университетларында) күзәтелми.

Әлеге күпкырлы эшчәнлек нәтиҗәсендә, XIX гасырның 30–40 нчы елларында университетның Көнчыгыш разряды каршында Казан тюркология мәктәбе оеша. Казан тюркология мәктәбенең башында торучылар, нигез салучылар булып И. Хәлфин, Х. Д. Френ, Ф. И. Эрдман, А. К. Казем-Бек, А. Троянский, И. Н. Березин, М. Мәхмүдов, А. Вагабов, М. Иванов, С. Кукляшев, К. Насыйри, Н. Ф. Катанов, В. В. Радлов һ. б. санала. Аларның күбесе энциклопедик эшчәнлеккә ия: бер үк вакытта тел белгече, тарихчы, фольклор белгече була, татар халкының рухи мәдәниятен төрле яссылыкта тикшерә, татар халкы тарихын һәм әдәби тел тарихын өйрәнә. Шул ук вакытта алар XIX гасырда татар җанлы сөйләм телен тикшерү, аерым төбәкләрдә яшәүче татарларның телләрен фәнни өйрәнүгә зур игътибар бирә.

XIX гасырда Казан университетында татар диалектологиясен өйрәнүне шартлы рәвештә ике чорга бүлеп карарга мөмкин: 1) XIX гасырның беренче яртысы – университет ачылганнан алып, Көнчыгыш разряды Санкт-Петербург

университетына күчерелгәнгә кадәр булган чор (1804–1854 еллар). Бу чор университетта татар телен укыта башлау; татар халкы тарихын, аның этнографиясен, татар телен фәнни тикшеренүнең киң җәелүе, университетта Көнчыгыш разряды ачылу һәм яшәеше белән бәйле; 2) XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башы (1855–1917), ягъни Көнчыгыш разряды Санкт-Петербург университетына күчерелгәннән алып, Октябрь инкыйлабына кадәр булган чорны колачлый. Бу этапта татар диалектларын өйрәнүдә университет каршында оешкан «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте» әгъзалары эшчәнлеге әһәмиятле роль уйный.

Җирле сөйләшләр буенча материаллар җыйнау өчен мөмкинлекләр артуга Россия хөкүмәтенең иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге дә сәбәпче була. Төрле шәһәрләрдә мәктәп-гимназияләрдә татар теле өйрәтелә башлый һәм, русларга татар теле укыту ихтыяҗыннан чыгып, ягъни миссионерлык максатларында, күп төрле практик кулланмалар төзелә, аларда җирле тел үзенчәлекләре дә чагылыш таба [4, б. 11-12].

Казан университетында беренче татар теле укытучысы булып Ибраһим Хәлфин (1778–1829) санала. Шуны да әйтергә кирәк: Хәлфиннәр династиясе (Сәгыйть Хәлфин, Исхак Хәлфин, Ибраһим Хәлфин) Беренче Казан гимназиясендә һәм Казан университетында 60 ел дәвамында (1769–1828) татар телен укыту юнәлешендә актив эш алып баралар. Татар телен укыту телне гамәли өйрәнүгә юнәлдерелгән була: кыска грамматик кагыйдәләрне үзләштерү, татар теленнән рус теленә һәм киресенчә тәрҗемәләр итү өчен күнегүләр бирелә, шулай ук сөйләмә телне өйрәнү һәм сөйләм практикасын алып баруга игътибар ителә. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: Ибраһим Хәлфин китаби иске татар телен укыта. Шул ук вакытта уку-укыту процессында һәм татар телен өйрәтү өчен төзелгән кулланма-әсбапларда Казан тирәсеннән җыелган тел материаллары файдаланыла, автор Казан татарлары телен әдәби норма итү юлында нәтиҗәле эшли.

1828 ел ахырында – 1829 ел башында университет ректоры Н. И. Лобачевский тырышлыгы белән, аның актив эшчәнлеге нәтиҗәсендә Көнчыгыш разряды («Восточный разряд») ачыла. Көнчыгыш разряды Казан тюркология мәктәбенең формашуына һәм үсеш алуына зур этәргеч бирә. Билгеле булганча, Казан тюркологлары мәктәбенең иң күренекле вәкилләре (И. Хәлфин, А. К. Казембек, И. Н. Березин һ. б.) телләрне чагыштырмача өйрәнүне беренче планга куялар, бу ысулның башкалардан өстенлеген исбатлыйлар. XIX гасырның беренче яртысында татар теленең җирле сөйләшләре, аларның тел үзенчәлекләрен турыдан-туры махсус тикшерүгә тиешенчә игътибар бирелмәсә дә, җанлы сөйләм телен өйрәнү юнәлешендә беренче тәҗрибәләр ясала.

Казан университеты профессоры Эрдман Франц Иванович (1793–1863) студентларга гарәп һәм фарсы телләрен укыта, көнчыгыш халыклары тарихын, бигрәк тә татарларны өйрәнүгә, төрки халыклар тарихы һәм филологиясе буенча чыганакларны ачыклауга зур игътибар бирә. Галимнең татар теленең тулы сүзлеген эшләү программасы аеруча әһәмиятле, әлеге программа 1830 ел башында эшләнә. Ф. И. Эрдман 1829 елның 29 сентябрендә университетның сүз гыйлеме бүлеге каршында татар теленең тулы сүзлеген эшләү тәкъдиме белән чыгыш ясый, программа татар теленең тулы грамматикасын һәм тулы сүзлеген төзүне максат итеп куя. Хезмәтнең сүзлек өлешен татар сөйләшләреннән җыелган лингвистик материалларга таянып эшләү күздә тотыла, Ф. И. Эрдман Казан, Әстерхан, Оренбург һәм Тубыл губернияләрендә яшәүче татарлар теленнән тупланган материал нигезендә сүзлек эшләргә мөмкин дип саный. Галимнең әлеге программасы университетның тел гыйлеме бүлеге утырышында кабул ителә, ләкин, кызганычка каршы, Мәскәүдә Халык мәгарифе министрлыгында яклау тапмый. Шулай итеп, төрки лингвистика үсеше өчен әһәмиятле булган татар теленең тулы сүзлеген төзү идеясе тормышка ашырылмыйча кала. Гыйльми советның программа мәсьәләсендә кабул ителгән карары Казан университетының тюркологик тикшеренүләр өлкәсендә үзәк булуын тагын бер кат раслый.

XIX гасырның беренче яртысында Көнчыгыш разрядта эшләгән Ибраһим Хәлфиннән соң икенче татар кешесе һәм татар теле укытучысы – Мөхәммәтгали Мәхмүдов (1824–1891). М. Мәхмүдов көнчыгыш каллиграфиясе белгече була, университетта төрек һәм татар телләреннән дәресләр алып бара, галим-тюрколог буларак исә Казан тюркология мәктәбе йогынтысында формалаша. Аның «Үлгән кебек булган кешеләрне кабергә күммәкдин саклауның гамәлләре бәянындадыр» (О предохранении обмерших от погребения) (1851), «Практическое руководство к изучению татарского языка» (1857) кебек хезмәтләре

басылып чыга, рус теленнән татарчага тәрҗемә итү белән дә шөгыльләнүе билгеле. Мөхәммәтгали Мәхмүдов, шул чорда киң таралган фикерләргә каршы чыгып, үзенең эшчәнлеге белән халыкның гади сөйләм телендә фәнни хезмәтләр язарга мөмкин булуны дәлилли. Медицинага караган һәм рус теленнән тәрҗемә ителгән хезмәтендә *мин фәкыйрегезне кара халык телендә тәрҗемә иткән өчен ачуланмагыз, бу китапчык һәр кеше укып аңласын өчен тәрҗемә ителде* [5, б. 79] дип ассызыклый. Төрки тел белемендә М. Мәхмүдовның «Практическое руководство к изучению татарского языка» (1857) хезмәте аеруча әһәмиятле дип санала. Хезмәтнең кереш өлешендә галим түбәндәгене билгеләп үтә: «бу китапны бастырганда, минем бердәнбер теләгем: рус ватандашларымны татар теле Казан сөйләме белән таныштыру иде» [6, б. 3]. Әлеге әсбапны казан татарларының сөйләмә теле буенча язылган беренче хезмәт дип атарга да мөмкин булыр иде [7, б. 23]. Әсбапны Казанның беренче гимназиясендә һәм Казан университетында татар теле укытуда дәреслек буларак куллануны истә тотып, шуны ассызыкларга мөмкин: XIX гасыр урталарында казан татарларының сөйләмә теле уку йортларында укытыла башлый, һәм алга таба казан татарлары сөйләше нигезендә татар әдәби теле формалаша.

Шулай итеп, XIX гасырның беренче яртысында Көнчыгыш разрядында эшләгән галимнәрнең һәм Казан тюркология мәктәбенең күренекле вәкилләренең фәнни эшчәнлеге нәтиҗәсендә җирле сөйләм теле материалларын фәнни әйләнешкә кертү, аларны уку-укыту процессында куллану юлында уңышлы тәҗрибәләр ясала. Әлеге материаллар алдагы этапта җанлы сөйләмә телне, халык сөйләшләрен фәнни өйрәнү, чагыштырма-тарихи юнәлештәге тикшеренүләр юлында ныклы нигез булып торалар.

XIX гасыр урталарыннан татар диалектларын һәм сөйләшләрен өйрәнүдә җанлану күзәтелә: аерым сөйләшләр буенча материаллар фәнгә кертелә башлый. XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башында (1855–1917) Казан университетында татар диалектологиясе мәсьәләләрен фәнни нигездә өйрәнү университет каршында оешкан «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте» эшчәнлеге белән бәйле үсеп китә. Билгеле булганча, әлеге җәмгыять университет каршында 1878 елда оештырыла һәм Идел буе халыкларының этнографиясен өйрәнүгә зур этәргеч бирә. Татар халкының рухи мәдәниятен, шул исәптән татар диалектларын өйрәнүдә булган традицияләр, җәмгыять эшчәнлегендә 1920 елларга кадәр үсеш-үзгәреш кичерә.

Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзаларының мөһим бурычларыннан берсе булып халык әдәбияты үрнәкләрен ачыклау: җырлар, әкиятләр, табышмаклар, риваятьләр җыю тора. Шулай ук алар текстларны тикшерү, төрле вариантларны чагыштыру һәм бастырып чыгару (берничә вариантта: оригинал телендә, академик фәндә кабул ителгән махсус билгеләрне кулланып эшләнгән фонетик язмада – транскрипциядә, рус теленә тәрҗемәдә) белән дә шөгыльләнгәннәр.

Җәмгыять эшчәнлегендә Идел буе халыкларының рухи һәм матди мәдәнияте буенча тикшеренүләр аерым урын алып тора, төрле халыкларның фольклорын, авыз иҗаты әсәрләрен чагыштырма аспектта өйрәнү юнәлешендә актив эш алып барыла. Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзаларының өйрәнү объектлары булып шулай ук рәсем һәм декоратив-гамәли сәнгать, архитектура, халык музыка культурасы һәйкәлләре дә тора. «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре»ндә дөнья күргән язмалар арасында тел тарихы, диалектология, палеография, текстология буенча эшләр бар.

XIX гасырның икенче яртысында татар сөйләшләрен һәм диалектларын фәнни өйрәнүгә нигез салына. Татар диалектологиясе фән буларак А. Г. Бессонов эшчәнлеге белән дөньяга туа [4, б. 13]. А.Г. Бессонов үзенең «О говорах казанского татарского наречия и об отношении его к ближайшим к нему наречиям и языкам» (1881) мәкаләсендә татар, мишәр, типтәр, «башкорт», керәшен сөйләшләрен тасвирлый, аларны чагыштырма метод нигезендә өйрәнеп, казан арты сөйләшләренә якын тору дәрәҗәләрен билгеләү омтылышы ясый, галим беренчеләрдән булып татар сөйләшләрен классификацияләп карый [8].

Татар диалектологиясе тарихында Казан университеты профессоры, чагыштырма тел белеме докторы, этнограф, фольклор белгече, танылган тюрколог Николай Фёдорович Катанов (1862–1922) хезмәтләре әһәмиятле урын алып тора. Н.Ф. Катанов 1894 елда университетның тарих-филология факультеты төрек-татар кафедрасы профессоры итеп билгеләнә. Н. Ф. Катановның көнчыгышны өйрәнү һәм фәнни-агарту өлкәсендәге күпкырлы эшчәнлеге Казанда шәрыкны өйрәнү фәненең сакланып

калуына һәм үсешенә ярдәм итә. Казан университетының Россиядә көнчыгышны өйрәнүнең зур үзәге буларак үсеп китүендә дә галимнең роле һәм әһәмияте бәяләп бетергесез.

1898–1914 елларда Н. Ф. Катанов Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятен җитәкли. Җәмгыятьтә татарларның төрле этник төркемнәрен: аеруча керәшеннәрне, мишәрләрне, типтәрләрне өйрәнүгә зур урын бирелә. Җәмгыятьнең гомуми җыелышларының берсендә мишәрләр телен тикшерү максатыннан махсус экспедицияләр оештыру кирәклеге турында карар кабул ителә [9, б. 449-450]. Төрки халыклар яшәгән регионнарга оештырылган кыр экспедицияләре вакытында халыкның рухи мәдәниятенә караган материалларны, фольклор үрнәкләрен җыйганда һәм язып алганда, җирле халыкның тел үзенчәлекләренә дә игътибар ителә. Шулай итеп, XIX гасыр ахырында җирле сөйләшләрне өйрәнү өчен урыннарга махсус экспедицияләр оештыру башланып китә. Экспедиция вакытында аерым төбәкләрдә яшәгән халыкның табигый сөйләме тыңлап-язып алына, диалектологик тикшеренүләрдә индивидуаль метод фәнни әйләнешкә керә, ул хәзерге вакытта да ышанычлы һәм продуктив методларның берсе булып санала.

Н. Ф. Катановның Казан чорына караган фәнни эшчәнлегендә дә төрки халыклар яшәгән төрле регионнарга кыр экспедицияләрен оештыру һәм аларда катнашу эше үзәктә тора. Аерым алганда, галим 1897 һәм 1898 елларда Уфа губернасының Минзәлә (1897 ел) һәм Бәләбәй (1897, 1898 еллар) өязләренә экспедицияләр оештыра [10; 11] һәм халкы төрле исемдә (татар, типтәр, мишәр, башкорт, чын башкорт) аталып йөртелгән авылларның сөйләшләрен чагыштырма планда өйрәнә, чын башкортлардан тыш булган авылларның сөйләше барысыныкы да бертөсле икәнлеген, һәм аларның татар теленә бик якын булуларын таный [4, б. 13]. Шулай ук Н. Ф. Катановның 1899 елның җәй айларында Себергә Енисей губернасына оештырылган экспедициядә катнашуы һәм себер татарларының сөйләм телен өйрәнүе дә мәгълүм [12], фәнни хисапта татар теленең көнчыгыш диалектларына күзәтү ясала.

Моннан тыш, XIX гасырның соңгы чирегендә – XX гасыр башында татар сөйләшләрен өйрәнүгә Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзалары яки җәмгыять белән тыгыз элемтәдә торган галимнәр – В. В. Радлов, С. Е. Малов, Г. Н. Әхмәров, В. К. Магницкий, В. А. Казаринов һ. б. үз өлешләрен кертәләр. Идел буе төрки халыклары арасында татарларның төрле этнографик төркемнәре – мишәрләр, типтәрләр, керәшеннәр тикшеренү объектлары итеп алына.

«Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре»ндә басылган күпчелек мәкаләләрдә мишәр диалектының аеруча күзгә ташлана торган фонетик һәм грамматик үзенчәлекләре күрсәтелә, алар казан арты сөйләшләре һәм керәшен татарлары сөйләшләренә хас үзенчәлекләр белән чагыштырыла, параллельләр китерелә. Җәмгыять галимнәренең һәм миссионерларның бу юнәлештә шактый тикшеренүләр үткәргәнлеге мәгълүм. Мәсәлән, С. Е. Малов Чистай өязендә экспедицияләрдә булып, ц-лаштыручы мишәрләр турында яза, мишәр диалектына хас шактый үзенчәлекләрне күрсәтә [13; 14]. Мишәрләр турында шулай ук В. К. Магницкий, В. А. Казаринов, Н. И. Золотницкийларның да күзәтүләре кызыклы. В. К. Магницкий Казан һәм Сембер өязе мишәрләрен [15], ә В. А. Казаринов Чистай өязе мишәрләрен [16] тикшерә.

Мишәр диалектын өйрәнүгә багышланган хезмәтләр арасында Г. Н. Әхмәровның фәнни тикшеренүләре аеруча игътибарга лаек, аларда үз халкы вәкиле тарафыннан җентекләп җыелган татарларның рухи мәдәнияте турында мәгълүматлар тәкъдим ителә. Г. Н. Әхмәровның «Мишәр халкы һәм аның теле турында» (1903) [17] мәкаләсе үзәк урынны алып тора. Галим 1894–1895 елларда Казан губернасының Спас һәм Тәтеш өязләренә фәнни командировкалары вакытында [18, б. 349] мишәрләрнең көнкүреше һәм теле турында мәгълүматлар җыя башлый, мишәр сөйләшләренең фонетик, лексик үзенчәлекләрен күзәтә. Бары тик 1903 елда гына Г. Н. Әхмәров фәнни эш нәтиҗәләрен тәкъдим итә ала. Тикшеренүнең төп максаты – тел үзенчәлекләре, риваятьләр, традицияләргә нигезләнеп, мишәрләрнең килеп чыгышын билгеләү [19, б. 184]. Татар-мишәрләрнең килеп чыгышын өйрәнгәндә, Г. Н. Әхмәров аларның гореф-гадәтләренә, риваятьләренә, үз күзәтүләренә һәм җирле топонимика, бигрәк тә, лингвистик материалларга таяна. Җыелган материалны өйрәнү һәм гомумиләштерү нигезендә Г. Н. Әхмәров беренчеләрдән булып мишәрләрнең төрки чыгышы турында фараз әйтә, бу исә XX гасырның икенче яртысында үткәрелгән этнографик тикшеренүләр белән раслана. Шуны искәртеп узарга кирәк: әлеге чордагы кайбер хезмәтләрдә (мәсәлән,

В. В. Вельяминов-Зернов, Е. А. Малов) мишәрләрнең килеп чыгышы угро-фин халыкларының тарихы белән тыгыз бәйләнештә аңлатыла.

Г. Н. Әхмәровның шулай ук типтәрләр һәм аларның килеп чыгышын тикшерүгә багышланган хезмәте [20] игътибарга лаек. Билгеле булганча, Г.Н. Әхмәров типтәрләр белән 1880 елларда, Нократ губернасының Алабуга өязендә укытучы булып эшләгән вакытта таныша [21, б. 355]. Галим 1904 елда мишәрләр, типтәрлар һәм башкортлар күпләп яшәгән урыннарга фәнни сәфәр – экспедиция планлаштыра, ләкин аның әлеге планы тормышка ашмыйча кала, һәм ул 1906 елда гына үзенең теләгенә ирешә.

Типтәрләрнең килеп чыгышын өйрәнү өчен фәнни әдәбият һәм мәгълүматлатның аз булуы сәбәпле, Г. Н. Әхмәровка үз күзәтүләренә таянырга туры килгән. Ул типтәрләр, татарларның башка этнографик төркемнәре һәм күрше халыкларның рухи мәдәниятләре элементларына тарихи-чагыштырма анализ ясый. Халыкның гореф-гадәтләре, төрле бәйрәмнәре, көнкүреше, традицион шөгыльләре тикшерелә; ономастик берәмлекләр анализлана. Үзенең тикшеренү мәгълүматларына нигезләнеп, галим типтәрләрне татар халкының бер этнографик төркеме итеп күрсәтә, «типтәр» этнонимының килеп чыгышы турында фәнни яктан расланган фикер әйтә (*типтәр* атамасы гарәп һәм фарсы телләреннән *дәфтәр* сүзе «исемлек, реестр» белән бәйләп аңлатыла). Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: XX гасыр башында Г. Н. Әхмәров тарафыннан тәкъдим ителгән «типтәр» атамасының килеп чыгышы турындагы фикере хәзерге фәндә раслана.

Шулай итеп, Г. Н. Әхмәровның татарның төрле этник төркемнәрен, аларның этнонимын, матди һәм рухи мәдәниятен тарихи һәм лингвистик аспектта өйрәнүгә багышланган хезмәтләре бүген дә фәнни даирәдә актуаль яңгырый, кызыксыну уята, аларда казан татарлары, мишәрләр һәм типтәрләр турында бай фактик материал тәкъдим ителә.

Димәк, XIX гасыр ахырында – XX гасыр башында ук татар диалектологиясенә фән буларак нигез салына һәм, диалект, сөйләшләргә бүленеш, аларны классификацияләү хакында да фикерләр күренә һәм бу процесс Казан университеты галимнәренең фәнни эшчәнлеге, гыйльми эзләнүләре белән дә тыгыз бәйләнә. Октябрь инкыйлабыннан соңгы елларда да диалектология фәненең бай һәм катлаулы үсеш юлында, сөйләшләрне системалы өйрәнүдә университет галимнәренең роле зур була.

Татар диалектологиясенең октябрь инкыйлабыннан соңгы чоры үзе 4 этапка бүлеп карала: 1) 1917–1940 еллар азагы, 2) 1940 еллар азагы – 1950 еллар, 3) 1950 еллар азагы – 1980 еллар, 4) 1980 еллар азагыннан хәзерге көнгә кадәр [4, б. 13].

Октябрь инкыйлабыннан соңгы чорда татар диалектологиясен өйрәнүдә Җамал Вәлиди (тулы исеме *Җамалетдин Җәләлетдин улы Вәлидов,* 1887–1932) эшчәнлеге игътибарга лаек. Ул – күренекле татар тел галиме, тәнкыйтьче, әдәбият белеме белгече, педагог. Җамал Вәлиди 1922–1923 елларда Казан университетының рабфагында укыта, 1923 елдан 1931 елның маена кадәр (кулга алынганчыга кадәр) Казан шәрык педагогия институтында укыта, фән белән шөгыльләнә. Җ. Вәлидинең анкета ысулын кулланып, җирле сөйләшләрдән тел материаллары туплавы, нократ сөйләше таралган якларга экспедицияләр уздыруы да билгеле. Әлеге эшчәнлек нәтиҗәсендә татар диалектларына кыскача характеристика, аларның классификациясе бирелә һәм татар сөйләшләрен өйрәнүгә багышланган мәкаләләр басыла [22], [23], [24].

Казан университетының күп кенә мөгаллим-галимнәре XX гасыр дәвамында татар диалектологиясе юнәлешендә актив эзләнүләр алып бара, аеруча Латыйф Җәләй, Диләрә Тумашева, Фәрит Юсупов кебек университет галимнәре татар диалектологиясен фәнни юнәлештә өйрәнүне нигезләүгә һәм үстерүгә зур өлеш кертә һәм уку йортында үзенең фәнни мәктәбен булдыра.

Латыйф Җәләй (тулы исеме *Латыйф Җәләлетдин улы Җәләлетдинов*, 1894–1966) – татар теле буенча беренче филология фәннәре докторы, профессор, тел белгече. Ул 1935 елдан үзенең педагогик эшчәнлеген башлый: югары уку йортларында – Казан педагогия институтында һәм Казан университетында татар диалектологиясе һәм татар теле тарихы фәннәрен укыта. Ул 1939 елдан 1962 елга кадәр Тел, әдәбият һәм тарих институтында татар теле секторын җитәкли; 1955 елда Мәскәүдә Тел белеме институтында татар теленең урта диалекты буенча докторлык диссертациясен уңышлы яклап, татар теле буенча беренче филология фәннәре докторы була, гомумән, 1940–1960 елларда татар диалектологиясе һәм татар теле тарихы өлкәсендә иң зур белгечләрдән санала.

Бу елларда Латыйф Җәләй татар диалектологиясе өлкәсендә актив тикшеренүләр алып бара: анкета ысулы нигезендә һәм индивидуаль методны кулланып, татар диалектлары буенча шактый материаллар материаллар җыя, аларны фәнни эшкәртә. Аның 19 тапкыр диалектологик экспедиция оештыруы һәм алар белән җитәкчелек итүе билгеле. Л. Җәләй, татар диалектологиясендә беренчеләрдән булып, тел үзенчәлекләрен картага төшереп карый, ягъни лингвистик география методын куллануның беренче тәҗрибәләрен ясый [4, б. 14].

Гамәли эшчәнлек нигезендә тупланган материалны эшкәртүнең һәм фәнни казанышларны системалаштыруның нәтиҗәсе буларак, галим 1947 елда югары уку йорты студентлары өчен «Татар диалектологиясе» (1947) исемле дәреслеген бастырып чыгара. Дәреслектә Татарстан һәм аннан читтәге өлкәләрдә һәм республикаларда татарган җирле сөйләшләр турында мәгълүматлар бирелә, татар диалектлары һәм сөйләшләренең территориаль-лингвистик принципка нигезләнеп төзелгән классификациясе китерелә [25]. Шунысын билгеләп үтәргә кирәк: әлеге дәреслек һәм галим тәкъдим иткән классификация бүгенге көндә дә үзенең актуальлеген югалтмый, студентларга татар диалектологиясе буенча язылган беренче дәреслек буларак тәкъдим ителә, татар диалектларын өйрәнү һәм уку-укыту процессында кулланыла. Татар диалектологиясенең татар тел белемендә мөстәкыйль тармак буларак үсеш алуында, аның югары уку йорты программаларына уку предметы буларак кертелүендә дә Л. Җәләй эшчәнлегенең әһәмияте зур.

Галим лингвистик материаллларга таянып, халыкның этногенезын өйрәнүне, аерым этник төркемнәр килеп чыгу, формалашу тарихын тикшерү юнәлешендә дә эш башкара. Татар халкы тарихы белән ныклап кызыксынган галим үзенең хезмәтләрендә татар теленең җирле төрки сөйләшләр нигезендә формалашканын раслый. Л. Җәләйнең «Татар тел белеме алдындагы бурычлар» (1956) мәкаләсендә татар теленең аңлатмалы сүзлеген, диалектологик атлас, диалектологик сүзлекне төзү һәм бастыру тәкъдиме белән чыга.

Казан дәүләт университетында татар диалектларын, Башкортстанда һәм Көнбатыш Себердә таралган татар сөйләшләрен экспедицияләр юлы белән өйрәнү, әлеге төбәкләргә диалектологик экспедицияләр оештыру 1956–1965 елларда яңадан башланып китә. Билгеле булганча, җанлы сөйләм телен тикшерү, җирле сөйләм үзенчәлекләрен экспедицияләр вакытында тыңлап-язып алу Казан тюркология мәктәбенә традицияләре барып тоташа. Университет укытучылары һәм студентлар зур булмаган төркемнәр булып, Башкортстанның көнбатыш районнарына һәм Көнбатыш Себергә диалектологик экспедицияләргә чыгалар, соңрак экспедицияләр Төмән, Омск, Новосибирск, Омск, Кемерево өлкәләренә кадәр җәелә. Диалектологик экспедицияләр вакытында җирле халыкның сөйләм үрнәкләре язып алына, тел материаллары туплана. Университет җитәкчелеге татар филологиясен үстерүне университетның мөһим бурычларыннан берсе буларак бәяли; экспедицияләр оештыруда, укытучы һәм студентларның диалектологик тикшеренүләренә һәр яктан ярдәм күрсәтә: матди яктан (мәсәлән, саз ягы татарларына экспедицияләр оештырганда, махсус киемнәр алырга ярдәм итә, вертолет һәм гидросамолет җәлеп итә) һәм фәнни аспектта (фәнни хезмәтләрне, тикшеренү нәтәҗәләрен бастырып чыгару мөмкинлекләре тудыра) нәтиҗәле эш алып бара. 1960 еллар ахырына себер татарлары диалектларын экспедиция юлы белән өйрәнү, нигездә, төгәлләнә. 1966–1975 еллар материалларны эшкәртү, нәтиҗәләрне гомумиләштерү һәм теоретик тикшеренүләр белән характерлана.

Әлеге чорда университетта татар диалектологиясе өлкәсендәге фәнни тикшеренүләр Диләрә Тумашева исеме һәм эшчәнлеге белән бәйләнеп китә. Диләрә Гариф кызы Тумашева (1926–2006) – филология фәннәре докторы, профессор, академик, тел белгече, галим-диалектолог; аның фәнни эшчәнлеге татар тел белеме тарихында һәм тюркологиядә күренекле урын тота, фәнни эзләнүләр белән янәшәдә, актив иҗтимагый эшчәнлек алып бара.

Д. Г. Тумашева татар диалектларын тикшерү мәсьәләләре белән 1949–1952 елларда Мәскәүдә Азия һәм Африка илләре институтының тюркология кафедрасында аспирантурада укыган вакытта ныклап шөгыльләнә башлый. Ул Н. К. Дмитриев җитәкчелегендә Себер татарлары диалектларын экспедицион тикшеренү юлы белән өйрәнә. Галимә 1952 елда Казан дәүләт университетына себер татарлары диалектлары буенча («Татарские диалекты Западной Сибири») кандидатлык диссертациясен яклап кайта һәм

алдагы тормышы, фәнни һәм педагогик эшчәнлеге Казан шәһәре һәм Казан дәүләт университеты белән бәйләнә.

Д. Г. Тумашева фәнни эшчәнлекне педагогик эшчәнлек белән тыгыз бәйләп алып бара: ул 1969 елда «Себер татарлары диалектларының татар һәм башка төрки телләргә мөнәсәбәте» темасына докторлык диссертациясен язып яклый.

Д. Г. Тумашева үзенең фәнни эзләнүләрендә Себер халыклары диалектларын беренче булып тикшергән күренекле тюрколог Василий Васильевич Радловның (1837–1918) эзләнүләрен үстереп алып китә. Галимә бу юлдагы эзләнүләрен Себер татарлары диалектларын өйрәнүдән башлап җибәрә: студентлар белән себер татарлары яшәгән төбәкләргә фәнни-диалектологик экспедицияләр оештыра, шул вакытта биредә яшәүчеләрнең җирле сөйләшләрен өйрәнә һәм аларны фәнни өйрәнү эшен җайга сала. Д. Г. Тумашева себер татарларның тел үзенчәлекләренә, халык авыз иҗатына, этнографиясенә, тарихына караган үзенчәлекле һәм бай материал җыеп кайта һәм аларны фәнни эшкәртеп, өч монография, күп сандагы мәкаләләр бастырып чыгара: «Көнбатыш себер татарлары теле (Грамматик очерк һәм сүзлек)» (1961), «Язык сибирских татар» (1968), «Диалекты сибирских татар: опыт сравнительного исследования» (1977).

Берничә дистә ел дәвамында Көнбатыш Себернең татар диалектларын фәнни һәм гамәли өйрәнү нәтиҗәсендә себер татарлары теле турында бөтенлекле караш формалаша. Мондый эзләнүләрнең чагыштырмача тарихи яссылыкта үстереп барылуы себер татарлары сөйләшләренең татар теле белән генә түгел, алтай, хакас, үзбәк, уйгур һәм кыпчак телләре белән дә бәйләнешләрен, уртак якларын аерып чыгарырга, диалектларның төрки телләр классификациясендәге урынын төгәлләштерергә юл ача.

Себер татарлары лексикасын тикшерү, лексик берәмлекләрне туплау эшен Д. Г. Тумашева алга таба да үстерә һәм камилләштерә һәм диалектның лексик үзенчәлекләрен этник яктан якын булган төрки телләр белән бәйле тикшерә башлый. Мондый эзләнүләр нәтиҗәсендә диалектларның һәм сөйләшләрнең территориаль таралыш картасы эшләнә, «Себер татарлары диалектлары сүзлеге» (1992) басылып чыга һәм фәнни җәмәгатьчелек тарафыннан югары бәяләнә.

Себер татарлары теленә караган фәнни эзләнүләренә бәйле Д. Г. Тумашева көнчыгыш диалектлар төркеменең диалект һәм сөйләшләргә бүленешен дә төгәлләштерә: Себер татарлары сөйләшенең тубыл-иртыш, бараба һәм том диалектларына бүленүен күрсәтә, аларның татар теле диалектлар системасына каравын бай фәнни һәм фактик материалларга таянып исбатлый. Аларның телен фонетик, лексик һәм грамматик үзенчәлекләр ягыннан ныклап өйрәнә, шулар нәтиҗәсендә диалектлар составында аерым сөйләшләрне аерып чыгара.

Д. Г. Тумашева мондый эзләнүләре белән төрки тел белемендә чагыштырма-тарихи тикшеренүләрнең чыганак базасын баетуга һәм камилләштерүгә ирешә һәм тарихи-лингвистик концепцияне фәнни әйләнешкә кертә. Аның нигезендә Себер татарлары диалектлары тарихи яктан киң Көнбатыш Себер ареалының төрле этник төркемнәренә караган телләргә һәм сөйләшләргә бәйләп аңлатыла.

Алдагы чорда да Казан университетында татар диалектологиясен фәнни өйрәнү дәвам итә: татар теленең диалектларын лингвистик география һәм ареал лингвистика методларына нигезләнеп өйрәнү өлкәсендә Фәрит Йосыф улы Юсупов зур уңышларга ирешә. Ф. Й. Юсупов – филология фәннәре докторы, профессор, танылган тел белгече, галим-диалектолог; ул лингвистик география һәм ареология өлкәләрендә фәнни тикшеренүләр алып бара.

Ул 1964 елдан татар теленең диалектларын лингвистик география һәм ареал лингвистика методларын кулланып тикшерү эшен башлап җибәрә. Татар халкы күпләп яши торган төбәкләргә фәнни-диалектологик экспедицияләр оештырып, халыкның җирле сөйләшләрен тикшерә, аларны фәнни эшкәртеп тә бара. Шул материалларга таянып, 1972 елда Ф. Й. Юсупов «Көньяк Урал һәм Урал арты сөйләшләре» дигән темага кандидатлык диссертациясен язып яклый (Н. Б. Борханова җитәкчелегендә). Курган һәм Чиләбе өлкәләрендәге моңа кадәр татар тел белемендә билгеле булмаган сөйләшләрне тикшерүгә караган бу хезмәт фәнгә күчле диалектолог, чит регионнарда яшәп килгән татар сөйләшләрен өйрәнүче зур белгеч килүен хәбәр итә.

1988 елда Казахстан Фәннәр Академиясенең Тел белеме институты каршында эшләп килгән докторлык диссертацияләрен яклау советында Ф. Ю. Юсупов «Татар фигыльләрен ареал ысул белән өйрәнү» дип аталган докторлык диссертациясен яклый (фәнни консультанты –

Ә. Р. Тенишев). Мәскәү яныннан алып, Ерак Көнчыгышка кадәрге татар сөйләшләренең ареал лингвистик зоналарын, тел үзенчәлекләрен өйрәнүгә багышланган әлеге хезмәт татар тел белемендә яңа сүз була. Бу эзләнүләре белән галим, татар диалектологиясе фәнендә беренче булып, өч диалектның классификацион билгеләрен аерып чыгара, *диалект теле* төшенчәсен киң фәнни әйләнешкә кертеп җибәрә.

Алга таба бу эзләнүләрнең дәвамы түбәндә Ф. Ю. Юсуповның «Көньяк Урал һәм Урал арты сөйләшләре» (1979), «Татар диалектлары. Урал сөйләшләре» (2003), «Красноуфим татарлары: тарих, тел, фольклор» (2003), «Сафакүл татарлары: тарих, тел, халык иҗаты» (2006) дигән монографияләре дөнья күрә һәм татар тел белемен, диалектология фәнен үстерүгә зур өлеш кертә. Лингвистик география һәм системалы-синхрон методларны кулланып язылган бу хезмәтләрдә Урал географик зонасында таралган красноуфим, нократ-кистем, эчкен, нагайбәк, сафакүл сөйләшләренең оешып китүе, этник тарихы, төп лингвистик хасиятләре тикшерелә. Лингвистик материаллардан тыш, архив материалларының, тарихи чыганакларның да кулланылуы әлеге монографияләрнең актуальлеген, фәнни кыйммәтен бермә-бер арттыра, сөйләшләрнең татар диалект системасындагы урыннарын төгәлләштерергә көчле нигез була.

Мондый эзләнүләрен Ф. Ю. Юсупов «Неличные формы глагола в диалектах татарского языка» (1985), «Изучение татарского глагола» (1986), кебек монографияләрендә, күпсанлы мәкаләләрендә, чыгышларында да үстереп, камилләштереп бара. Аның «Морфология татарского диалектного языка» (2004) монографиясен Россия Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы филология буенча укыту-методик берләшмәсе Россия Федерациясенең классик университетларының милли бүлекләре өчен дәреслек буларак тәкъдим итә, ул Казан дәүләт университетында гуманитар фәннәр арасында үткәрелгән конкурста 2005 елның иң яхшы фәнни хезмәте исеменә лаек дип табыла.

Ф. Ю. Юсупов бүгенге көндә дә татар диалектларын системалы тикшерү юнәлешендә киңкырлы эш алып бара. Аның күпьеллык фәнни эшчәнлеген тупланган «Казан татарлары шивәсе» (2023) хезмәтендә Казан ханлыгы чоры, Казан ханлыгы җимерелгәннән соң татар әдәби теленең нигезен тәшкил иткән, бай сөйләшләр системасыннан торган казан татарлары шивәсенең (диалектының) барлыкка килү тарихы, аның авазлар системасын һәм грамматик төзелеше өйрәнелә. Китапта шулай ук сөйләшләрне формалаштырган этник төркемнәрнең тарихына да кызыклы күзәтүләр ясала. Казан татарлары шивәсенең башка төрки телләр белән территориаль мөнәсәбәтен ачыклау өчен галим тел белеменең лингвистик алымнарын да киң куллана [26].

Казан университетында татар диалектологиясен өйрәнү юнәлеше XX гасыр ахыры – XXI гасыр башында дәвам итә. Олпат галимнәребезнең эшен дәвам итеп, бу юнәлештә Г. М. Сөнгатов, М. Р. Саттарова (Хәбибуллина), Г. Ч. Фәйзуллинаның һ. б. татар диалектологиясе буенча якланган кандидатлык һәм докторлык диссертацияләрен күрсәтергә мөмкин. 1988–1989 елларда Түмән өлкәсендәге саз ягы татарлары телен өйрәнү өчен Г. М. Сөнгатов җитәкчелегендә диалектологик экспедицияләр оештырыла, сөйләшнең фонетик системасы эксперименталь юл белән тикшерелә [27]. М. Р. Саттарова татар диалект телендә [а] фонемасының вариантларын өйрәнә, аларның таралыш киңлекләрен билгели [28]. Г. Ч. Фәйзуллинаның докторлык диссертациясендә Түмән өлкәсенең көньягында таралган татар халык сөйләшләре материалы нигезендә диалекталь тел картинасында кеше образы бирелеше лингвокультурологик аспектта тикшерелә [29].

Казан университетында татар диалектларын һәм сөйләшләрен экспедиция юлы белән тикшерү эше дәвам итә. Мәсәлән, Г. Р. Галиуллина, Ә. Ш. Юсупова, Э. Х. Кадыйровалар 2015–2016 елларда Мордовия һәм Чувашстан Республикалары, Пенза өлкәсендә яшәүче татарларның сөйләм телен өйрәнү максатыннан оештырылган диалектологик экспедиция материалларын фәнни эшкәртеп, монографияләр бастырдылар [30, б. 9].

Казан университеты укытучылары аерым татар сөйләшләрен монографик тикшерүгә дә зур өлеш кертә. Мәсәлән, З.Н. Кириллованың Төркиянең Фырат университеты профессоры Әрҗан Алкая белән берлектә басылган монографиясендә керәшен татарлары сөйләшләре тикшерелә, аларның тел һәм мәдәни үзенчәлекләре тасвирлана [31]; моннан тыш татар сөйләшләрнең лингвистик үзенчәлекләрен тарихи-чагыштырмалы тикшерүне максат итеп куйган күпсанлы мәкаләләр басыла [32], [33].

Соңгы елларда татар теле белеме кафедрасы мөгаллим-галимнәре күренекле диалектолог һәм тюркологларның фәнни мирасын кабат гыйльми кулланылышка кертү, аларны киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим итү юнәлешендә актив эшчәнлек алып баралар. Әлеге юнәлештә Санкт-Петербург Фәннәр академиясе профессоры, тарихчы Г. Ф. Миллер (1705–1783) тарафыннан Бөек Төньяк экспедициясе вакытында (1733–1743) тупланган һәм диалектологик тикшеренүләрдә галимнәр игътибарыннан читтә кала килгән материаллар киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителде [2, б. 267]. Шунысы әһәмиятле: әлеге кульъязмалар һәм сүзлекләр татар сөйләшләрен өйрәнүдә беренче чыганаклар булып торалар.

Татар диалектлары һәм сөйләшләренең формалашу тарихын өйрәнү, XIX гасыр – XX башы язма ядкярләрдә чагылыш тапкан лингвистик үзенчәлекләр нигезендә аерым этник төркемнәрне, аларның тел системасын тикшерү татар тел белемендә актуаль мәсьәләләр булып кала, әлеге юнәлештә Ф. Ш. Нуриева мәкаләләрен аерып күрсәтергә мөмкин [34], [35].

Татар теле белеме кафедрасында татар диалектологиясе өлкәсендә яшь белгечләр – фәнни алмаш әзерләүгә аерым игътибар бирелә. XXI гасырның беренче чирегендә диалектологик экспедицияләр оештыру дәвам итә (җитәкчесе – башта Э. Х. Кадыйрова, соңрак А. Ф. Юсупов), университет укытучылары һәм студентлары, Россиянең төрле төбәкләрен булып, җирле сөйләм үрнәкләрен җыю белән шөгыльләнәләр. Мәсәлән, Курган өлкәсенең Сафакүл һәм Шадринск районнарына (2005–2007), Төмән өлкәсенә (2012–2013), Түбән Новгород өлкәсенә (2015), Мордовия Республикасы һәм Пенза өлкәсенә (2015), Чувашстан Республикасына (2016) диалектологик экспедицияләр оештырылды. Соңгы елларда студентлар Татарстан Республикасының Казан арты районнарында – Биектау (2019), Арча (2021), Әтнә (2023) районында экспедицияләрдә булдылар.

## Төп нәтиҗәләр

Тюркологиядә һәм татар тел белемендә татар диалектологиясен өйрәнүнең бай тәҗрибәсе тупланган. Әйтергә кирәк: Казан университетында татар диалектларын һәм сөйләшләрен фәнни яктан өйрәнү университет ачылган вакыттан алып, хәзерге көнгә кадәр эзлекле, системалы төстә алып барыла: XIX гасырның беренче яртысында (1804–1854 еллар) татар халкы тарихын, аның этнографиясен, диалектология мәсьәләләрен өйрәнү Көнчыгыш разряды эшчәнлеге белән бәйле үстерелә; XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башында (1855–1917) татар диалектларын өйрәнүдә университет каршында оешкан «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте» эшчәнлеге әһәмиятле урын тота, әлеге чорда татар диалектологиясенә фән буларак нигез салына. XX гасырның икенче яртысы – XXI гасыр башы аралыгында татар диалектологиясен өйрәнүдә аерым фәнни мәктәпләр формалашып җитә: университет галимнәре татар диалектологиясе тарихының һәр чорында фәнни эзләнүләргә саллы өлеш кертеп, аерым юнәлешләргә нигез салалар һәм шул юнәлештә актив эзләнүләр алып баралар, кандидатлык, докторлык диссертацияләрен яклатып, үз укучыларын әзерлиләр. Шушы дәвердә университетта студентларга диалектология предметын укыту һәм фәнни тикшеренүләр алып бару, татарлар компактлы яшәгән территорияләргә экспедицияләр оештыруда Л. Җәләй, Д. Г. Тумашева, Г. Ф. Саттаров, Ф. Й. Юсупов, Г. М. Сөнгатов, Э. Х. Кадыйрова, О. Р. Хисамов, А. Ф. Юсупов кебек күренекле галим-диалектологлар әйдәп бара.

Казан университеты тюркология һәм татар тел белеме үсешенә, фәнни алмаш әзерләүгә дә зур өлеш кертә. Университетның берничә кафедрасында татар диалектологиясе буенча төрле дәрәҗәдәге күпсанлы диссертацияләр тикшерү узып, диссертация яклау советларында якланган, яңа фән кандидатлары һәм докторлары әзерләнә. Татар теле тарихы һәм татар диалектологиясен өйрәнүгә зур өлеш керткән галимнәрнең фәнни-методик мирасын ачыклауга, аларның якты истәлегенә багышланган фәнни-гамәли конференцияләр, искә алу кичәләре үткәрелә, җыентыклар һәм конференция материаллары басылып чыга.

Казан университетында озак еллар дәвамында студентларга татар диалектологиясен укытуның бай тәҗрибәсе тупланган. Фәнни тикшеренү нәтиҗәләрен һәм казанышларны системалаштыру нәтиҗәсендә, студентларга белем бирү өчен дәреслекләр, уку-укыту әсбаплары һәм программалар язылган, фәнни-методик юнәлештә бүгенге көндә тотрыклы система оешкан.

**Әдәбият**


1. *Миллер Г. Ф.* Описание живущих в Казанской губернии языческих народов, яко то черемис, чуваш и вотяков: с показанием их жительства, политического учреждения. СПб.: Имп. Акад. наук, 1791. 99, [2] с., [8] л.

2. *Nurieva F. Sh., Galiullina G. R., Yusupov A. F.* G.F.Miller's Dictionary "Description of Pagan Peoples Living in Kazan Province, such as Cheremis, Chuvash and Votyaks..." as a Valuable Source for Studying the Tatar Language of the 18th Century (based on LingvoDoc material) // Trudy ISP RAN / Proc. ISP RAS, vol. 35, issue 6, 2023. P. 265–282.

3. *Миллер Г. Ф.* История Сибири. М.-Л.: Изд-во Акад. наук СССР. 1937–1941. Т. 1., 1937. 608 с.

4. Татар халык сөйләшләре: ике китапта / [авторлар коллективы: Ф. С. Баязитова и др.]. Казан: Мәгариф, 2008. Кит. 1. 2008. 461 б.

5. *Мәхмүдов М. Г.* Үлгән кебек булган кешеләрне кабергә күммәкдин саклауның гамәлләре бәяныйдадыр. Казан, 1851. 82 б.

6. *Махмудов М. Г.* Практическое руководство к изучению татарского языка. Казань: Изд-во книгопродавца Ивана Дубровина, 1857. 255 с.

7. Казанская лингвистическая школа: Книга первая: Казанская тюркская лингвистическая школа / Сост. М. З. Закиев. Казань: Татар. кн. изд-во, 2008. 424 с.

8. *Бессонов А. Г.* О говорах казанского татарского наречия и об отношении его к ближайшим к нему наречиям и языкам // Журнал Министерства народного просвещения. Ч. CCXVI. СПб.: Типография В. С. Балашева, 1881 (август). С. 200–242.

9. Протоколы общих собраний Общества археологии, истории и этнографии за 1898 г. // Известия Общества археологии, истории и этнографии при Казан. университете. 1899. Т. 15. Вып. 4. С. 442–482.

10. Отчет о поездке, совершенной с 1 июня 1897 г. по 20 августа того же года в Белебеевский и Мензелинский уезды Уфимской губернии // Ученые записки Казанского университета. Кн. 11. Казань, 1898. С. 1–37.

11. Отчет о поездке, совершенной с 20 мая по 20 августа 1898 г. в Белебеевский уезд Уфимской губернии // Ученые записки Казанского университета. Кн. 7 и 8. Казань, 1900. С. 1–30.

12. Отчет о поездке в Минусинский уезд Енисейской губернии, совершенной по поручению историко-филологического факультета императорского Казан. университета, летом 1899 года. Казань, 1900. 59 с.

13. *Малов Е. А.* Сведения о мишарях: этнографический очерк // Известия Общества археологии, истории и этнографии. 1885. Т. 4. С. 13–91.

14. *Малов Е. А.* Из поездки к мишарям (о наречии мишарей Чистопольского уезда) // Приложение к «Ученые записки Казанского университета». Кн. 4. Казань: Типография литогр. ун-та, 1904. С. 1–24.

15. *Магницкий В. К.* Несколько данных о мишарях (мещера, мещеряки) и селениях их в Казанской и Симбирской губерниях // Известия Общества археологии, истории и этнографии. 1896. Т. 13, Вып. 4. С. 245–257.

16. *Казаринов В.А.* О мишарях в Чистопольском уезде Казанской губернии // Известия Общества археологии, истории и этнографии. 1885. Т. 4. С. 1-12.

17. *Ахмаров Г. Н.* О языке и народности мишарей // Известия Общества археологии, истории и этнографии при Казан. университете. 1903. Т. 19, Вып. 2. С. 91–160.

18. *Салахова Э.К.* Проблема происхождения татар-мишарей и тептярей в трудах Г. Н. Ахмарова // Историческая этнология. 2016. Т. 1. № 2. С. 349–362.

19. *Марданова Ф. Ф.* Роль Казанского университета в изучении духовной культуры татар Поволжья // Ученые записки Казанского университета. Сер. Гуманит. науки. 2020. Т. 162, Кн. 3. С. 181–195.

20. *Ахмаров Г. Н.* Тептяри и их происхождение // Известия Общества археологии, истории и этнографии при Казан. университете. 1908. Т. 23, Вып. 5. С. 340–364.

21. *Салахова Э.К.* Проблема происхождения татар-мишарей и тептярей в трудах Г. Н. Ахмарова // Историческая этнология. 2016. Т. 1. № 2. С. 349–362.

22. *Валиди Дж.* О диалектах казанского татарского языка // Вестник научного общества татароведения. 1927. № 6. С. 50–65;

23. *Вәлиди Җ.* Нократ һәм Глазов татарлары арасында // Татарстан. 1929. № 5. С. 40–42;

24. *Валиди Дж.* Наречие каринских и глазовских татар // Труды общества изучения Татарстана. 1930, Т. 1. С. 135–144.

25. *Җәләй Л.* Татар диалектологиясе: югары уку йортлары һәм педагогия училищелары студентлары өчен дәреслек. Казан, 1947. 137 б.

26. *Юсупов Ф. Ю.* Казан татарлары шивәсе. Казан: Татар. кит. нәшр., 2023. 993 б.

27. *Сунгатов Г. М.* Фонетическая система заболотного говора тоболо-иртышского диалекта сибирских татар (экспериментально-фонетическое исследование): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1991. 23 с.

28. *Хабибуллина М. Р.* Характеристика изоглосс вариантов фонемы [а] в татарском лингвинистичеком пространстве: дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2002. 173 л.

29. *Файзуллина Г. Ч.* Образ человека в диалектной языковой картине мира (на материале татарских народных говоров юга Тюменской

области): дис ... д-ра филол. наук. Казань, 2017. 406 л.

30. *Кадирова Э. Х., Галиуллина Г. Р., Сайфулина Ф. С., Юсупова Ә. Ш.* Мордовия Республикасы һәм Пенза өлкәсе татарлары: диалектология һәм халык авыз иҗаты материаллары. Казан, 2015. 313 б.

31. *Alkaya E., Kirillova Z.* Kreşin Tatar Türkçesi (Dil, Tarih, Kültür). İstanbul: Kesit Yay., 2018. 670 s.

32. *Кириллова З. Н., Алкая Ә.* Керәшен татарлары сөйләшләренең лексик үзенчәлекләре // Tatarica. 2018. № 2 (11). Б. 7–30.

33. *Юсупов А. Ф.* Русские заимствования в татарских говорах: особенности функционирования и адаптации // Филология и культура. Philology and Culture. 2023. № 3 (73). С. 81–86.

34. *Норманская Ю. В., Нуриева Ф. Ш.* Графико-фонетические особенности диалектов татар-кряшен в конце XIX – начале XX в. // Кириллические памятники на уральских и алтайских языках. I том. Графико-фонетические особенности книг XIX в. М.: Изд. группа «Альма Матер». С. 339–354.

35. *Нуриева Ф. Ш.* Языковой памятник говора сергачских мишарей: текст исповеди XIX в. // Кириллические памятники на уральских и алтайских языках. I том. Графико-фонетические особенности книг XIX в. М.: Изд. группа «Альма Матер». С. 354–370.

# ШКОЛА ТАТАРСКОЙ ДИАЛЕКТОЛОГИИ В КАЗАНСКОМ УНИВЕРСИТЕТЕ: ПРЕДПОСЫЛКИ, ФОРМИРОВАНИЕ И РАЗВИТИЕ

**Айрат Фаикович Юсупов**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
faikovich@mail.ru.

**Гузель Чахфаровна Файзуллина**,
Тюменский государственный университет,
Россия, 625003, г. Тюмень, ул. Володарского, д. 6,
utgus@mail.ru.

Диалектология – одно из развитых научных направлений в татарском языкознании, основной задачей которой является изучение живого разговорного языка коренных народов и местных говоров, исследование явлений народной речи, не вошедших в литературный язык, определение территории их распространения.

В течение нескольких столетий велась последовательная, систематическая научная работа по изучению духовной культуры татарского народа, истории различных этнических групп, особенностей их языка, их быта и образа жизни, обычаев. Работа по изучению живой речи, фиксации материалов, относящихся к отдельным говорам и диалектам татарского языка, сбору фактического материала, научному его толкованию началась еще в первой половине XVIII века. Изучение татарской диалектологии в Казанском университете также имеет более чем двухвековую историю, и в этом направлении накоплен богатый опыт, исследования татарских диалектов и говоров в университете продолжаются и в настоящее время, оставаясь одним из наиболее актуальных и востребованных научных направлений кафедры татарского языкознания. Основным объектом изучения в статье является формирование и развитие диалектологической школы в Казанском университете, данная научная проблема впервые подвергается комплексному исследованию. Это определяет научную новизну и актуальность статьи. В ходе изучения диалектологической школы выявляются основные этапы развития, исследуется научная и научно-методическая деятельность ведущих ученых, внесших большой вклад в изучение татарской диалектологии.

**Ключевые слова:** татарская диалектология, татарские ученые, ученые-диалектологи, кафедра татарского языка, Казанский университет